җирләрдә урнаштыру әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтада каралган форма буенча гариза нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

4) 20 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сезонлы СБСОны урнаштыруга шартнамә әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымтада каралган форма буенча 180 көннән артмаган срокка төзелә.»;

5) 23 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«Кабул итү комиссиясе тарафыннан сезонлы СБСОны урнаштыруга шартнамә шартларының бозылуы ачыкланган очракта, сәүдә субъекты кимчелекләрне 30 календарь көн эчендә бетерергә бурычлы. Әгәр билгеләнгән срок узуга кимчелекләр бетерелмәсә, Башкарма комитет шартнамәне суд тәртибендә өзәргә хокуклы.»;

6) 24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24. Әгәр сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты, җәмәгать туклануы объекты кабул итү комиссиясе актыннан башка эксплуатацияләнсә, Башкарма комитет шартнамәне суд тәртибендә өзәргә хокуклы, сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты, җәмәгать туклануы объекты демонтажланырга тиеш.»;

7) түбәндәге эчтәлектәге 25.1. пункт өстәргә:

«25.1. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру рөхсәт ителми:

1) инженерлык челтәрләренең сак зонасында, тимер юлүткәргечләре һәм автомобиль эстакадалары астында, шулай ук җир асты җәяүлеләр кичүләренә керү (чыгу) урыннарыннан 5 метрлы сак зонасында;

2) бина аркаларында, газоннарда, чәчәклекләрдә, балалар мәйданчыкларында, ял мәйданчыкларында, спорт мәйданчыкларында, торак йортлар, биналар тәрәзәләреннән, стационар сәүдә объектлары витриналарыннан 20 метрдан ким булган арада;

3) пассажирлар транспортының тукталыш пунктларында, шулай ук утырту мәйданчыклары чикләреннән 10 метрлы зонада;

4) автомобиль юлын төзү (реконструкцияләү) максатларында формалаштырылган җир участогы чикләрендә мондый төзелеш (реконструкция) һәм проектлана торган башка объектлар линияләрен төзү тәмамланганчы;

5) җайга салынмый торган чатларда һәм урамнар һәм юллар тоташкан урында күренә торган өчпочмак чикләрендә;

6) тротуарларда, велосипед һәм җәяүлеләр юлларында;

7) җәяүлеләр кичүе чигенә кадәр 5 метрдан ким булган арада;

8) агач кәүсәләренә кадәр, яктырту һәм башка баганаларга кадәр 3 метрдан ким булган арада;

9) суперсайт һәм медиаэкран күчәренә кадәр 10 метрдан ким булган арада;

10) пилларс күчәренә, реклама стеласына һәм пилон күчәренә кадәр 5 метрдан ким булган арада;

11) закон белән билгеләнгән башка очракларда.»;

8) 26 пунктта:

- 3, 4, 7 пунктчалары үз көчен югалткан дип танырга;

- 5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) сәүдә субъекты тарафыннан сезонлы СБСОны урнаштыруга шартнамә буенча рәттән ике айдан артык түләү кертелмәү;»

9) 28 пунктның икенче абзацында «14 (ундүрт) эш көне эчендә» сүзләрен «5 (биш) календарь көн эчендә» сүзләренә алмаштырырга»;

